**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 13 гыйнвар | № 5

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 октябрь, 744 нче, 2015 ел, 25 февраль, 113 нче, 2015 ел, 25 апрель, 286 нчы, 2016 ел, 8 февраль, 78 нче, 2016 ел, 6 август, 532 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты аппараты хезмәткәрләренең чик санын 28 берәмлек күләмендә вазыйфаи окладлар буенча 140,0 мең сум суммада айлык түләү фонды белән;»;

әлеге карар белән расланган ихтыяҗлары өчен Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты алып килеп бирүчеләрне (подрядчыларны, үтәүчеләрне) билгеләү функцияләрен гамәлгә ашырган Татарстан Республикасы дәүләт заказчылары һәм Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре исемлегенең 30 пункты үз көчен югалаткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\5.docx